КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 31 гыйнвар г.Казань № 50

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 9 март, 133 нче; 2016 ел, 8 май, 286 нчы; 2016 ел, 21 июнь, 419 нчы; 2016 ел, 4 октябрь, 715 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 968 нче; 2017 ел, 6 июнь, 345 нче; 2017 ел, 21 ноябрь, 894 нче; 2017 ел, 30 декабрь, 1133 нче; 2019 ел, 16 февраль, 111 нче; 2019 ел, 5 сентябрь, 774 нче; 2019 ел, 17 октябрь, 923 нче; 2020 ел, 14 апрель, 285 нче; 2020 ел, 30 июнь, 548 нче; 2020 ел, 16 июль, 600 нче; 2020 ел, 3 сентябрь, 779 нчы; 2021 ел, 15 февраль, 82 нче; 2021 ел, 5 май, 309 нчы; 2021 ел, 8 июнь, 442 нче; 2021 ел, 16 август, 731 нче; 2021 ел, 6 октябрь, 954 нче; 2021 ел, 22 ноябрь, 1109 нчы; 2022 ел, 3 февраль, 81 нче; 2022 ел, 29 сентябрь, 1047 нче; 2022 ел, 31 октябрь, 1159 нчы; 2022 ел, 20 декабрь, 1375 нче; 2023 ел, 24 февраль, 182 нче; 2023 ел, 25 апрель, 524 нче; 2023 ел, 2 май, 555 нче; 2023 ел, 27 июль, 899 нчы; 2023 ел, 4 сентябрь, 1067 нче, 2023 ел, 19 октябрь,

1323 нче, 2023 ел, 11 декабрь, 1599 нчы, 2023 ел, 19 декабрь, 1645 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5.1.1. пунтта «*******» астөшермәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«******* – 2022 елның 24 февраленнән Украина, Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы территорияләрендә, 2022 елның 30 сентябреннән Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операция барышында Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны башкаруга булышлык күрсәтүче оешмалар белән контракт төзегән (башка хокук мөнәсәбәтләренә ия булган), әлеге бурычларны үтәүгә ярдәм итү бурычларын башкаруга бәйле рәвештә алынган яралану, контузия, гариплек яки авыру аркасында инвалид булган, даими тәрбиягә мохтаҗлар затлар «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Идел» инвалидларын социаль реабилитацияләү республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә урнашканда өстәмә тапшырыла.»;

5.1.2 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1.2. инвалидларны тернәкләндерү үзәкләренә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренә кергәндә I төркем инвалидларны (әлеге Тәртипнең 5.4.2 пунктының алтынчы абзацында күрсәтелгән затлардан тыш), сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балаларны, өченче дәрәҗәдәге теләсә кайсы категориядәге тормыш эшчәнлеге чикләнгән 7 яшькә кадәрге инвалид балаларны озатып йөрүче затларга бирелергә тиешле документлар (алга таба - озатып йөрүчеләр):»;

5.2.3 пунктның «л» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«л) әлеге Тәртипнең 5.4.2 пунктының алтынчы абзацында күрсәтелгән затларга.»;

5.4.1$^{1}$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4.1$^{1}$. Әлеге Тәртипнең 5.4.2 пунктының алтынчы абзацында күрсәтелгән затлар өчен «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Идел» инвалидларын социаль реабилитацияләү республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә күрсәтелә торган социаль хезмәтләрнең исемнәре, тасвирламасы һәм аларны күрсәтү күләмнәре әлеге Тәртипкә 41 нче кушымтада күрсәтелгән.»;

5.4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4.2. Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәтләр түбәндәгеләргә күрсәтелә:

социаль-тернәкләндерү бүлекләрендә – даими булышлык күрсәтеп торуга мохтаҗ 18 яшьтәге һәм өлкәнрәк инвалидларга, «Иминият пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә җиткән гражданнарга;

инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә: 18 яшьтәге һәм өлкәнрәк инвалидларга;

мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә: инвалид балаларга; 0 яшьтән алып 3 яшькә кадәр сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән, инвалидлыгы булмаган балаларга;

Социаль хезмәтләр күрсәтү социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең эш көннәрендә исәпләнә һәм инвалид балалар, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә инвалид балалар өчен – 21 эш көненә кадәр, социаль-тернәкләндерү бүлекләрендә инвалидлар һәм өлкән яштәге гражданнар өчен – 15 эш көне, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә инвалидлар өчен – 15 эш көне тәшкил итәргә тиеш (әлеге пунктның алтынчы абзацында күрсәтелгән очрактан тыш).

2022 елның 24 февраленнән Украина, Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы территорияләрендә, 2022 елның 30 сентябреннән Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операция барышында Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны башкаруга булышлык күрсәтүче оешмалар белән контракт төзегән (башка хокук мөнәсәбәтләренә ия булган), әлеге бурычларны үтәүгә ярдәм итү бурычларын башкаруга бәйле рәвештә алынган яралану, контузия, гариплек яки авыру аркасында инвалид булган, даими тәрбиягә мохтаҗлар затларга «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Идел» инвалидларын социаль реабилитацияләү республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәт күрсәтүләр дәвамлылыгы 90 эш көне тәшкил итә.

Социаль-тернәкләндерү бүлекләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү ешлыгы елына ике тапкыр; инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә - ике елга бер тапкыр, әлеге пунктның алтынчы абзацында күрсәтелгән очрактан тыш. Инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә буш урыннар булганда (чират булмаганда) инвалидларга социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәтләрдән файдалану мөмкинлеге елына бер тапкыр бирелә.

Әлеге пунктның алтынчы абзацында күрсәтелгән очракта социаль хезмәтләр күрсәтү ешлыгы елына ике тапкыр тәшкил итә.

Инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә инвалидлар (әлеге пунктның алтынчы абзацында күрсәтелгән очрактан тыш), инвалид балалар өчен стационар формада социаль хезмәт күрсәтү срогы инвалидның (аның законлы вәкиленең), инвалид баланың законлы вәкиленең социаль хезмәт күрсәтү срогы тәмамланганга кадәр социаль хезмәтләр күрсәтүченең эш көннәрендә исәпләнә торган биш көннән дә соңга калмыйча бирелгән тиешле гаризасы нигезендә (социаль хезмәтләр күрсәтүченең эш көннәрендә исәпләнә торган иң күбе 30 көнгә) озайтыла.

Социаль хезмәт күрсәтү срогын озайту турында карар социаль хезмәтләрдән файдаланучының мотивацион әзерлеге (тернәкләндерү дәресләрендә даими булу, тәкъдимнәрне үтәү) һәм тернәкләндерү чараларын уздыру нәтиҗәсендә уңай динамикасы булганда кимендә социаль хезмәтләр күрсәтү срогы тәмамлану көненә кадәр социаль хезмәтләр белән тәэмин итүченең эш көннәрендә исәпләнә торган

кимендә өч көн кала кабул ителә. Социаль хезмәт күрсәтү срогын озайту турында кабул ителгән карар хакында социаль хезмәтләрдән файдаланучыга (аның законлы вәкиленә) социаль хезмәт күрсәтү срогын озайту турында карар кабул ителгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүче социаль хезмәтләр күрсәтүнең соңгы көнендә социаль хезмәтләрдән файдаланучы (аның законлы вәкиле) белән социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы шартнамәгә өстәмә килешү төзи, ул социаль хезмәт күрсәтү вакытын озайту турында кабул ителгән карар нигезендә озайтыла.»;

әлеге Тәртипкә 41 нче кушымтаның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2022 елның 24 февраленнән Украина, Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы территорияләрендә, 2022 елның 30 сентябреннән Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операция барышында Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны башкаруга булышлык күрсәтүче оешмалар белән контракт төзегән (башка хокук мөнәсәбәтләренә ия булган), әлеге бурычларны үтәүгә ярдәм итү бурычларын башкаруга бәйле рәвештә алынган яралану, контузия, гариплек яки авыру аркасында инвалид булган, даими тәрбиягә мохтаҗлар затларга «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Идел» инвалидларын социаль реабилитацияләү республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәт күрсәтүләр исеме, тасвирламасы һәм аларны күрсәтү күләмнәре».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин